*Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение*
*« Мортовская основная общеобразовательная школа»*
*Елабужского муниципального района Республики Татарстан*

*Спецвыпуск школьной газеты*

# За знание Белем өчен

Укытучылар һәм укучылар газетасы



## *АНАЛАРНЫҢ КУЛЫН ҮБИК*

Нәни кызым минем кулымны үпте.

Сабыемның бу назы минем күңелемдә хисләр өермәсе куптарды. Күз карашымны еракларга төбәп, мин уйга калдым.

...Могҗиза булсын иде дә, еллар йомгагын, кино тасмасы кебек бер-бер артлы сүтеп, гомер юлыңа күз салсаң иде! Син дөньяга килгәннән алып, ана кешенең армый-талмый, сәгатьләр саен, көннәр буе, еллар дәвамында синең турында кайгыртуын, үзе капмый, иң тәмле ризыгын сиңа сузуын, балам, дип, яну-көюен, аерылган чакларда аналарга гына хас көчле сагыну хисләрен тоя, беләалсаң иде! Ананың олы йөрәге биргәннең тамчысын да калдырмыйча, бирәчәк бурыч кебек, анаңа кайтара алсаң иде!

Сабыем минем кулымны үпте…Ә мин үптем микән?..Замандаш! Синең булдымы әниеңнең кулын үпкәнең? Без үптекме? Замандаш!

Дөньяда иң кадерле кеше-газиз әниең алдындагы бурычыңны син ничек кайтарасың? Ананың иксез-чиксез назы, йөрәк җылысына син ничек җавап бирәсең? Онытмадыңмы син әниеңне? Рәнҗетмәдеңме аны? Аңа кырыс караш ташламадыңмы? Күз яшьләренә сәбәпче булмадыңмы?

Нарасыем минем кулымны үбә… Ул шулай минем яратуымны белдерә. Шундый рәхәт, гүя ул минем кулымны түгел, йөрәгемне үбә…

Баласының һәр көне өчен сулкылдаган аналар кулын үбик!

***Невозможно поспорить с тем, что День Матери — праздник вечности. Из поколения в поколение для каждого человека мама — самый главный человек в жизни. Становясь матерью, женщина открывает в себе лучшие качества: доброту, любовь и заботу. Молодой праздник — День матери — постепенно входит в российские дома. И это замечательно: в рабочие будни у нас часто не хватает времени говорить то, что должны, День Матери—это повод сказать своим мамам то, как ты их любишь. Так не упускайте же возможности, говорите им как они много для вас значат! Поздравляем всех матерей с этим праздником. Пусть на ваших лицах всегда светится улыбка и радостные искорки сверкают в глазах.***



25 ноября—День Матери. Для каждого из нас слово «мама» означает, что-то родное ласковое, нежное. Когда произноситься это слово, в каждом из нас возникает какое-то теплое чувство, какой-то нежный огонек загорается в наших сердцах. Давай те же в этот день устроим нашим мамам приятный сюрприз: какой-нибудь милый подарок, или просто обняв или поцеловав, скажем эти заветные слова: «Я люблю тебя, Мама!»

Нуриахметова Зилия, 6 класс

Берегите своих матерей!

Какими бы взрослыми, сильными, умными, красивыми мы ни стали, как бы далеко жизнь ни увела нас от родительского крова, мама всегда остается для нас мамой, а мы - ее детьми.

Смехов Никита, 6 класс






**Әниемә...**

Әнием минем, яратам сине!
Кочагыма алып , үбәмен сине.
Синең ягымлы карашың җылыта мине,
Синең йомшак кулларың назлыйлар мине.

Син булсаң яннарымда -
Бик рәхәт миңа!
Сәламәтлек, ак бәхетләр
Телим мин сиңа!

Һәркемнең дә әнисе бар,
Әнинең кадерен белик.
Әни – ул тормыш бизәге,
Аңа кү-ү-п еллар телик!

Әхтәмова Зөһрә, 6 сыйныф

Мама...Сколько добра, света и тепла излучает это слово, как оно приятно звучит. Кажется, нет слова роднее, чем это. А почему? Потому что мама – это самый близкий, самый родной человек для любого из нас. Что бы ни случилось, ты знаешь, что мама всегда поймет, всегда выслушает и поддержит тебя в любом случае, она единственная, кому ты можешь доверить свои самые сокровенные тайны, планы, надежды…

Гайнанова Азалия, 6 класс



**Мамочка, любимая, ты моя родная.**
**Лучшая на свете, точно знаю я.**
**Ты одна, мамуля, добрая такая.**
**Самая пресамая мамочка моя.**



## *ВО СЛАВУ МАТЕРИ*

В нашей стране День Матери стали отмечать сравнительно недавно. 30 ноября 1998 года указом Президента Российской Федерации Б. Н. Ельцина утвержден ежегодный праздник - День Матери, который празднуется в последнее воскресенье ноября. Инициатива учреждения Дня матери принадлежит Комитету Государственной Думы по делам женщин, семьи и молодежи. По официальным данным, сегодня матерями в нашей стране являются более 50 миллионов женщин, из них более 1 млн. 700 тыс. – многодетные. Российских матерей всегда отличали щедрость души, преданность, самопожертвование, любовь и великое терпение. И сегодня они бережно хранят семейный очаг, учат детей добру, взаимопониманию, нравственности. Официальное объяснение этого праздника таково. День Матери отвечает лучшим традициям отношения россиян к материнству, объединяет все слои российского общества на идеях добра и почитания женщины-Матери. По смыслу и содержанию это самый святой праздник.

«МАМА- это имя Бога на устах и в сердцах маленьких детей»

Н.Некрасов




### *Притча о матери*

За день до своего рождения ребенок спросил у Бога:

- Говорят, завтра меня посылают на Землю. Как же я буду там жить, ведь я так мал и беззащитен?

Бог ответил:

- Я подарю тебе ангела, который будет ждать тебя и заботиться о тебе.

Ребенок задумался, затем сказал снова:

- Здесь на Небесах я лишь пою и смеюсь, этого достаточно мне для счастья.

Бог ответил:

- Твой ангел будет петь и улыбаться для тебя, ты почувствуешь его любовь и будешь счастлив.

- О! Но как я пойму его, ведь я не знаю его языка? – спросил ребенок, пристально глядя на Бога. – А что мне делать, если я захочу обратиться к тебе?

Бог мягко прикоснулся к детской головке и сказал:

- Твой ангел сложит твои руки вместе и научит тебя молиться.

Затем ребенок спросил:

- Я слышал, что на Земле есть зло. Кто защитит меня?

- Твой ангел защитит тебя, даже рискуя собственной жизнью.

- Мне будет грустно, так как я не смогу больше видеть тебя…

- Твой ангел расскажет тебе обо мне все и покажет путь, как вернуться ко мне. Так что я всегда буду рядом с тобой.

В этот момент с Земли стали доноситься голоса; и ребенок в спешке спросил:

- Боже, скажи же мне, как зовут моего ангела?

- Его имя не имеет значения. Ты будешь просто называть его Мама.

# БЕРЕГИТЕ МАТЕРЕЙ

**Мамочка, любимая, ты моя родная.**
**Лучшая на свете, точно знаю я.**
**Ты одна, мамуля, добрая такая.**
**Самая пре  самая мамочка моя.**



Мама - первое слово,
Главное слово в каждой судьбе.
Мама жизнь подарила,
Мир подарила мне и тебе.






Ана баласының якын дусты һәм киңәшчесе ул. Беркемгә дә сөйли алмый торган эч серләрен әнигә , тик әнигә генә сөйләргә була. Үсеп кеше булгач та ана баласын оныт-мый, авыр вакытларда аңа беренче булып ярдәм кулын суза. Менә шундый тиңдәшсез кеше ул- Ана.

**Так нежен свет твоих лучистых глаз,**
**И ласковые руки так красивы!**
**Я, мамочка, хочу, чтоб каждый час**
**Был для тебя особенным, счастливым,**
**Чтоб день с улыбки начинала ты,**
**Вокруг встречала, радость, пониманье,**
**Чтоб исполнялись все твои мечты**
**И самые заветные желанья!**





Моя любимая мамочка!




**День матери – праздник великий, святой –**
**Сегодня проходит по свету.**
**Сегодня весь мир поклоняется той,**
**Которой счастливее нету,**
**Кто ночи не спал и покой наш берег**
**Кто сильный и праведный самый,**
**Наш друг и товарищ, врач и педагог…**
**С Днем матери, милая мама!**

**Дорогая Бабушка!**

**Не считай понапрасну года,**
**Не грусти, что виски поседели.**
**Так бывает в природе всегда:**
**Это след оставляют метели.**
**Пусть нелегкой была твоя жизнь,**
**Были все ж в ней и радость, и счастье.**
**Ты крепись, дорогая, держись,**
**Обойдут стороною ненастья.**
**Ведь богатство твое - это МЫ:**
**Дочка, сын, внуки, правнуки даже!**
**Долго-долго еще ты живи,**
**Чтоб пра-правнуков тоже понянчить!!!**

# Әбием истәлекләре...



Мин, Мазитова (кыз фамилиям Нургалеева) Гөлнур Нургали кызы, 1936 елның 26 мартында Морт авылында туганмын. Бала чагым жиңелләрдән булмады. 1941 елда немецлар һөҗүм итеп, бик аяныч сугыш башланды. Сугыш чыкканда мина бары 5 яшь кенә иде. Шундый авыр вакытта, 1941 елның 1-июлендә, авылыбыздан барлык жегәрле ирләрне сугышка алдылар, алар арасында минем әти дә бар иде. Ул киткәндә без өч бала калдык: иң кечесе Рәшит булды. Әни таң атканда иртән иртүк урак урырга китеп, кич, кояш баегач кына кайта иде. Без өйдә өч бала ачлы-туклы әнине көтеп утыра идек. Әти бер кулы гарипләнеп 4 ел йөреп кайтты.

Гомер узып барды, һәм мин 1943 елда 1 нче сыйныфка укырга кердем. Ул елларда балалар бик күп иде. Ике беренче класс бар иде: берсе «А» , икенчесе «Б» классы. Булмәләрдә бик суык булганлыктан, жылыныр өчен утын ягалар иде. Укытучылар жәй көннәрендә, укыту эшләреннән тыш, урманга төшеп утын әзерлиләр иде. Авыр сугыш вакытлары булуга карамастан, укытучылар безгә,укучыларга, һәрвакытта да бик яхшы мөгалләмәдә булдылар, бар эштә дә ярдәм иттеләр, төпле белемнәр бирергә тырыштылар. Мин уземне укыткан беренче укытучымны һич тә оныта алмыйм, анын мәрхәмәтлелеге, ягымлылыгы,матур карашлары гел искә төшә. Хафизова Нурия Гайнетдиновна иде ул. Нурия апа класста суык булганлыктан, безгә хәтта баш киемнәрендә салырга кушмый иде. Уку йортларын гына тәмамлап килгән яшь укытучыларыбызда бар иде: немец теле укытучысы Нина Сергеевна, рус теле укытучысы Нина Архиповна. Алар шулай ук безгә карата бик ягымлы булдылар. Дәфтәрләр булмаганлыктан, иске китапларга яздык, ә ручкаларны тал чыбыгыннан ясап перо тыгып куя идек.

7 сыйныф бетереп, мин почтага хат ташучы булып эшкә кердем. Эшкә урнашып, паспорт алгач, Пермь якларына китеп Кизел шәхәренә барып урнаштым. Анда 5 ел шахтада эшләдем. Аннан сон шахтадан хатын-кызларны эштән чыгаралар дигән хәбәрне ишеткәч, сату эшенә укырга кердем. Укып бетереп, уземне сату эшенә багышлап бик куп еллар эшләдем.

Кизел шәһәрендә уземнен гомерлек иптәшемне, куп еллар электр челтәрендә эшләгән Зелендольский егете, Рәшитне очраттым. Анын белән өйләнешеп, туган авылым- Мортка кайттык. Өч малай үстердек: Наиль, Равиль, Ильшат. Аллага шөкер өчеседә үз тормышларын кордылар, балалар үстереп бәхетле гомер итәләр. Мин узем кече улым- Ильшат гаиләсендә, оныкларым янәшәсендә гомер итәм. Мин үземне картлык көнемдә бик бәхетле кешегә саныйм.

Барлык теләкләрем дә шул: кешеләр бер- берсе белән дус-тату яшәп, сугышлар булмасын иде. Балалар бәхетле, тәртипле һәм намуслы булып үссеннәр иде. Без кургәннәрне аларга күрергә язмасын.

**Мазитова Резеда, 8 сыйныф укучысы**

# Гаилә альбомындагы рәсем



1941-1945 елгы Бөек Ватан сугышы инде хәтергә әверелеп бара. Җиңүгә зур өлеш керткән баһадирларыбызның күбесе бу фани дөньядан китеп барды. Күпме газиз җаннарның гомерләре чит-ят җирләрдә өзелде. Сугыш афәте һәммә кеше өчен уртак. Бу уртаклык - кайгы, сагыш, югалту.

Мин **Алабуга районы Морт урта мәктәбенең 5 нче сыйныфында укыйм, исемем Зилия.** Һәр елны Җиңү көне якынлашкан саен, минем дулкынлануым арта төшә.

Ник дисәгез, минем бабам Шәкүр, әтиемнең әтисе - сугыш ветераны. Дәһшәтле сугыш еллары турында сөйләгәндә, бабамның йөзләре кырыслана төшә, күрсенә, авыр сулый иде. Күрәсең, ул сугыш кырларында ятып калган фронтташ дусларын исенә төшерә.

Кызганыч, бабам чираттагы 70 нче Җиңү язын каршылый алмый инде, ул вафат. Мин аны бик сагынам, аның медальләрен йомшак кына итеп сыпырып куям. Еш кына без, гаиләбез белән җыйналгач, фоторәсемнәр карыйбыз.

Гаилә альбомында сакланган бер рәсем мине бик кызыксындырды, мин икенче бабам Миннәхмәттән “Бабам, син сугышта булдыңмыни?- дип сорадым. Ә әниемнең әтисенә 65 яшь, ул 1944 елда туган. “Юк”,- дип елмайды бабам,- “ мин бит “копия"- диде ул. Бабамның бабасы Шакирҗан Исмәгыйль белән Миннеасма гаиләсендә 1890 елда дөньяга килә. Алар аерым хуҗалык булып яшәгәннәр. Терлек тотканнар, яшелчә, җиләк- җимеш бакчалары булган. Бабамның яшьлек еллары революция, гражданнар сугышы елларына туры килгән, 1918 елда Шакирҗан бабам белән Минзифа әбиемнең уллары туган, аңа Миннәхмәт дип исем кушканнар. Ул 1930 елга кадәр Морт мәктәбендә белем ала. 1934 елда тракторчылар курсын тәмамлап, Морт МТСында эшли башлаган. 1938 елда Кызыл Армия сафларына алынган. Иле-без чикләрен сакларга киткән егет Фин сугышына эләгә. Совет-фин сугышы озакка сузыла, куәтле чик буе ныгытмаларын штурмлау, көтелгәнгә караганда, күпкә кыенрак булып чыга. Сан ягыннан финнардан өстен булса да, бу сугышта Кызыл Армия зур корбаннар бирә.

1940 елның мартында СССР белән Финляндия арасында солых килешүенә кул куела. Сугыш бетү шатлыгы озакка бармый. Фин сугышыннан соң озак та үтми, 1941 елда Бөек Ватан сугышы башлана, билгеле инде Миннәхмәт абыйларга өйгә кайту хыялда гына кала. 23 яшьлек егетләр танк егәрли. 1941 ел октябренең беренче атнасында сан ягыннан өстен немецлар берничә юнәлештә фронтны өзәләр. Ачылган урыннарга танк дивизияләре кертәләр. Катлаулы хәл туа. Германия танклары тизлек белән Мәскәүгә якынлаша. Немецлар һөҗүме Мәскәүне саклаучыларның көчле каршылыгына очрый. Башкаланы бер селтәнүдә алу омтылышы уңышсыз тәмамлана.

1941 елның декабрендә яңа көчләр белән тулыландырылган Кызыл Армия, дошман көтмәгәндә, контрһөҗүмгә күчә. Миннәхмәт абыйларның танк дивизиясе дә бу аяусыз бәрелештә катнаша, инде 1942 елның 7 гыйнварына немец гаскәрләрен Мәскәүдән 100-250 чакрымга артка чигенергә мәҗбүр итәләр. Контрһөҗүм вакытында Кызыл Армия шактый күп кешесен югалта. Кече сержант Миннәхмәт Шакирҗан улы танк экипажы да батырларча сугышып һәлак була. Тверь өлкәсенең Бельский районы, Озеренск авылындагы туганнар каберлегендә Морт егете 24 яшьлек Миннәхмәт тә күмелгән. “Улыгыз батырларча һәлак булды”, дигән хәбәр Морт авылында яшәүче Шакирҗан бабамнар гаиләсенә килеп ирешә. Ике елдан соң алар гаиләсендә бер малай туа, аңа сугыш кырында ятып калган батыр егет хөрмәтенә Миннәхмәт дип исем кушалар. Дөрес, һәркемнең үз гомере, ә бу очракта менә ничек булыр иде бит диярге мөмкин. Минем бабам Миннәхмәт шулай ук Совет Армиясендә хезмәт итеп үз бурычын үтәп кайткан, армиядән кайткач лаеклы ялга чыкканчы трактор иярләгән. Бабам авылда бик хөрмәтле кеше, аның медальләре, Мактау кәгазьләре бар. Әбием Дания белән бер кыз һәм дүрт малай тәрбияләп үстергәннәр. Сугыш булмаса, Миннәхмәт абый 24 яшендә үлмәс, нәселебез тагын да тармаклы булыр иде, дип уйлыйм. Минем теләгем: беркайчан да сугышлар булмасын. Җир йөзендәге халыклар тату яшәсеннәр, шатлансыннар, җырласыннар, биесеннәр - менә безнең кебек. Минем язмада сүз фоторәсемнәр турында барды. Киләчәк буыннар альбомнарында сугыш сүрәтләре түгел, ә менә шат балалар рәсемнәре генә күрсеннәр.

**Нуриәхмәтова Зилия, 5 нче сыйныф укучысы**

## Учителя-ветераны, участники Великой Отечественной войны




Ерак Көнчыгышта 183 нче полкта хезмәт итә. Хәрби осталык, батырлык һәм тапкырлык күрсәткәне өчен“За отвагу” медале белән бүләкләнә.
1962 нче елдан мәктәптә эшли.




Участвовал на Калининском и III Белорусском фронтов. Награждён медалями «За отвагу», «За победу над Германией», «За взятие Кенигсберга». С 1954 года преподавал в школе Начальную Военную Подготовку.

**Это удивительные, честные, героические люди. О них можно говорить очень много . Они для нас всегда будут примером. Мы гордимся ими.**

## Зиннуров Абдул Зиннурович



1943 нче елда 10 гвардия һава десанты дивизиясе составында Абдул Украина җирләрен азат итә. Аягын снаряд кыйпылчыгы көйдереп ала. Бик озак дәваланганнан соң, 1944елда протез киеп,III дәрәҗә Дан ордены кавалеры Абдул Зиннурович туган авылына кайта. Мәктәптә сызым фәнен укыта.

200 нче укчы полкта сугышны сапёр булып башлый һәм пулемётчы булып бетерә. Сталинград сугышында катнаша. Сугыштан соң мәктәптә укучыларга биология һәм география серләрен ачарга ярдәм итә. Аларда туган як табигатенә мәхәббәт хисләре тәрбияли.

## Аглямов Муллахмат Аглямович



## Ганеев Гариф Ганеевич



Курск, Орёл, Белград, Гомель, Мозер, Климович, Рогачев шәһәрләрен азат итүдә катнаша, “Батырлыклар өчен” медале белән бүләкләнә. 1958 елдан мәктәптә хезмәт дәресләрен укыта.

Над номером работали: главный редактор: Сабирзянова Э., ответственные за выпуск: Голушко Э.,Мазитова Р., Исрафилова А., ИбатуллинаЗ.,Юнусова Р..
Фоторепортаж:Гайнанова А., Ахтямова З., НуриахметоваЗ.
Адрес: МБОУ «Мортовская средняя общеобразовательная школа»
423630, РТ, Елабужский район, с.Морты, ул.Молодёжная-2, д.20.
Тел:+7(855) - 577-42-67, e mail^Smort.elb@edu.tatar.ru